| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

29.04.2021 Казан ш. № 1386-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 15.12.2014 № 2881-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Кадастр Недвижимости» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы һәм “Казан шәһәре (өлешчә) территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 15.12.2014 № 2881-р карары (алга таба - № 2881-р Карар) белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз

Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милкендә булган, 4437 м озынлыктагы, 29261, 9556 инвентарь номерлы газүткәргечләрнең 16:33:180201:1012, 16:33:180201:1063 кадастр номерлы җир кишәрлекләре өлешләрендәге саклау зонасын бетерергә.

2. Түбән басымлы газүткәргечне күчерү сәбәпле «Кадастр Недвижимости» ҖЧҖ тарафыннан 2016 елның 15 декабреннән 16 декабренә кадәр әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милкендә булган, 4381,5 м озынлыктагы, әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газүткәргечнең әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклык зонасы чикләрен расларга.

3. 29261, 9556 инвентарь номерлы газүткәргечләрнең эксплуатация срогында саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «Кадастр Недвижимости» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир асты газүткәргеченең характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 2881-р Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.1 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры килгән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә урнаштырылган 375,5975 км озынлыктагы ЭПУ «Приволжскгаз» газ бүлү газүткәргечен РКЦ «Земля» ҖЧҖ тарафыннан 2014 елның сентябреннән октябренә кадәр әзерләнгән һәм 2014 елның 19 ноябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ тарафыннан килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасына (планына) нигезләнеп.»;

1 нче кушымтада 29261, 9556 инвентарь номерлы газүткәргечкә туры килгән юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 29261, 9556 | | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авыл җирлеге | 4381,5 | d = 160 түбән басым | 16:24-6:2001-233.1 от 02.11.2001 |

16:33:180201:1012, 16:33:180201:1063 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә туры килгән юларны 2 нче кушымтадан төшереп калдырырга;

2 нче кушымтаны әлене карарның 1 нче кушымтасына туры килгән юллар белән тулыландырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**